# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Уразлы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**29 октябрь 2023 ел** **№4**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 29 октябрьдә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар Җыенының йомгаклау беркетмәсе төзелде 2023 елда «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Уразлы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда 2200 сум күләмендә үзара салым кертергә
һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

1) - зиратны төзекләндерү;
2)- электр баганалары һәм яктырткычлар урнаштыру;
3) - территорияне төзекләндерү (күпернең перильле коймасын буяу);

**“ ӘЙЕ”** **“КАРШЫ”**

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегендә 100 кеше,
Халык җыенында 61 кеше тавыш бирүдә катнашты
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:
“ӘЙЕ” позициясе өчен җыенда 61 кеше тавыш бирде;
“КАРШЫ” позициясе өчен җыенда 0 кеше тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлегенең Уразлы торак пунктында гражданнар җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танылды.

2. "Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Уразлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш 2024 елда 2200 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә

1) - зиратны төзекләндерү;
2)- электр баганалары һәм яктырткычлар урнаштыру;
3) - территорияне төзекләндерү (күпернең перильле коймасын буяу);

3. Олы Җәке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән гражданнар җыены нәтиҗәләрен халыкка җиткерергә, Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы Ф. А. Фәйзуллина